УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ
ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ
СОСТОЯНИЕМ
САМОХОДНЫХ МАШИН И
ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ
БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ
ТЕХНИК ТОРЫШЫНА
КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

---

ПРИКАЗ
20.06.2018

Казан ш.

БОЕРЫК
01-05/164-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник
күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук
бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү
факты турында эшкә алучы вәкиленә
хәбәр итү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 04 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэминат секторына дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Дәүләт техник күзәтчелек
идарәсенең 2018 елның 20
июнендәге 01-05/164-пр
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук
бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында эшкә
алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 5 өлеше нигезендә эшләнде.

2. Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә (алга таба – Идарә) үзләре өчен Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) эшкә алучының вәкиле булып торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) үзләрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәр итү процедурасын регламентлый.

3. Коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү, әлеге фактлар буенча тикшерү уздырылган яки уздырыла торган очраклардан тыш, граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычы булып тора.

4. Идарә башлыгына коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәрләмә (алга таба – Хәбәрләмә) граждан хезмәткәре тарафыннан Тәртипнең 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, язмача формада төзелә.

Хәбәрләмәдә түбәндәге белешмәләр чагылдырылырга тиеш:

Хәбәрләмә җибәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, биләгән вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе;

коррупциячел хокук бозуларга этәрүче физик (юридик) зат турында мәгълүм булган барлык белешмәләр;

Идарәдәге граждан хезмәткәренә, үзенең хезмәт бурычларын үтәвенә бәйле рәвештә, нинди дә булса затларның үзен коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактына җирлек туган (очраклар турында мәгълүм булган) хәлләргә (датасы, урыны, вакыты, башка шартлары) тасвирлама;

граждан хезмәткәренә килгән, коррупциячел хокук бозуга этәрү турында

таныклаучы мөрәҗәгатькә җентекле тасвирлама (хезмәткәргә карата зат тарафыннан башкарылган гамәлләр, тәкъдимнәр, гаризалар, таләпләр, башкача формадагы мөрәҗәгатьләр), шулай ук граждан хезмәткәре шуны кылу өчен этәрелгән, коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләргә тасвирлама;

коррупциячел хокук бозуларга этәрү ысулы һәм хәлләре (сатып алу, янау, алдау һ.б.), шулай ук затның коррупциячел хокук бозуларны кылу турында тәкъдимне кабул итүдән баш тартуы (ризалашуы) турында мәгълүмат;

Хәбәрләмәне прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (нинди) җибәрү датасы.

5. Хәбәрләмәгә нинди дә булса затларның граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү хәлләрен раслаучы булган барлык материаллар теркәп куела.

6. Хәбәрләмә Идарә башлыгы (аның бурычларын үтәүче зат) исеменә рәсмиләштерелә һәм коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка, ул булмый торган очракта – оештыру-хокук эше бүлеге башлыгына (алга таба – Җаваплы зат) кичекмәстән, әгәр күрсәтелгән тәкъдим хезмәттән тыш вакытта килсә, хезмәтне үтү урынына килү белән кичекмәстән тапшырыла.

7. Граждан хезмәткәре вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәмәгән урында яки даими хезмәт итү урыныннан читтә булганда Хәбәрләмә почтадан юллап, алга таба Хәбәрләмәнең төп нөсхәсен хезмәткә кайту белән Җаваплы затка тапшыру юлы белән, факсимиль элемтә каналлары яки мөмкин булган бүтән электрон элемтә каналлары аша җибәрелергә мөмкин.

8. Җаваплы зат Хәбәрләмәне 2 нче кушымтага ярашлы рәвештәге формада дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәрләрне теркәү журналында (алга таба – журнал) терки. Журнал тегелгән, номерланган һәм Идарә мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

9. Хәбәрләмә журналда теркәлгәннән соң дәүләт хезмәткәренә Хәбәрләмне алган зат турында белешмәләрне һәм аны теркәүгә алу датасын күрсәтеп, Хәбәрләмәнең күчермәсе кул куйдыртып тапшырыла. Хәбәрләмә почта аша килгән очракта, Хәбәрләмәнең күчермәсе Хәбәрләмәне почта аша җибәргән граждан хезмәткәренә заказлы хат белән җибәрелә.

Хәбәрләмәне теркәүдән баш тарту, шулай ук Хәбәрләмә күчермәсен тапшырмау – рөхсәт ителми.

10. Алынган белешмәләрнең конфиденциальлеге «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп тәэмин ителә.

11. Җаваплы зат Хәбәрләмәне теркәгән көнне аны, эчке эшләр органнарына яки башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итү өчен, Идарә башлыгына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

12. Идарә башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Хәбәрләмне Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнарына, Татарстан Республикасы

буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясенең Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсенә юллау турында карар кабул иткән очракта, Җаваплы зат, материалларын теркәп, журналда теркәүгә алган датадан башлап 10 календарь көненнән соңга калмыйча, Хәбәрләмәнең җибәрелүен гамәлгә ашыра. Хәбәрләмә бер үк вакытта санап үткән барча дәүләт органнарына да, шулай ук компетенциясе буенча берсенә генә дә җибәрелергә мөмкин. Хәбәрләмә бер үк вакытта берничә дәүләт органына җибәрелгән очракта, теркәлгән хатта чыккан хатларның реквизитларын күрсәтеп, барча адресатлар күрсәтелә.

13. Эшкә алучы вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына үзен коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр иткән граждан хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.

14. Идарәдәге дәүләт хезмәткәренең эшкә алучы вәкиленә коррупциячел хокук бозуларны кылуга этәрү фактлары турында хәбәр итү бурычын үтәмәве аның дәүләт хезмәтеннән куылуына яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төрле җаваплылык төрләренә җәлеп итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгына

________________________________________
(Ф.И.А., биләнә торган вазыйфа,
________________________________________
структур бүлекчә,
________________________________________
яшәгән урын адресы, телефон номеры)

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү

____________________________________________________________________
__________________________________________________________________
ягыннан мине коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәр итәм

____________________________________________________________________
(хокук бозуга этәрә торган затның Ф.И.А., вазыйфасы, аның турында мәгълүм булган барлык белешмәләр)

Хокук бозуга этәрү минем тарафтан түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру максатларында булды:

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(граждан хезмәткәренә килгән, коррупциячел хокук бозуга этәрү турында таныклаучы мөрәҗәгатькә җентекле тасвирлама (хезмәткәргә карата зат тарафыннан башкарылган гамәлләр, тәкъдимнәр, гаризалар, таләпләр, башкача формадагы мөрәҗәгатьләр), шулай ук граждан хезмәткәрен шуны кылу өчен этәрелгән, коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләргә тасвирлама күрсәтелә)

Хокук бозуга этәрү түбәндәгечә гамәлгә ашырылды

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(этәрү ысулы һәм хәлләре,сатып алу, янау, алдау һ.б., шулай ук затның коррупциячел хокук бозуларны кылу турында тәкъдимне кабул итүдән баш тартуы (ризалашуы) турында мәгълүмат)

Хокук бозуга этәрү башкарылды ___________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(телефоннан сөйләшкәндә, шәхсән очрашу барышында, смс-хәбәр белән һ.б.)

Хокук бозу этәрү булды: _____сәг. _____мин. «__»_______ 20___ел, ________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(шәһәр, адрес)

Шулай ук түбәндәгеләргә хәбәр итү хакында хәбәр итәм

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (нинди) хәбәр итү датасы)

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү факты турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибенә 2 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәрләмәләрне теркәү журналы

| № п/п | Хәбәрне теркәү датасы | Хәбәрне тапшырган затның Ф.И.А., вазыйфасы | Хәбәрне тапшырган затның имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |